КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 май г.Казань № 416

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1172 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6, 17 һәм 19 нчы пунктлары нигезләмәсе 2019 елның 24 сентябреннән төзелгән субсидия бирү турындагы килешүләргә карата кулланыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 3 нче пункт өстәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия идарә итүче компания тарафыннан агымдагы финанс елында расланган бизнес-план нигезендә бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча фактта тотылган, агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артмаган чыгымнар күләмендә бирелә.

Чыгымнарны каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$С_{вз} = З_1 + З_2 + З_3 +... + З_n,$$

монда:

$С_{вз}$– субсидия күләме;

$З_1$,$З_2$, $З_3$ … $З_n$ – түбәндәге чыгымнар юнәлешләре буенча бу пунктның беренче абзацы нигезендә өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча фактта тотылган чыгымнар: авторлык күзәтчелеген, проект-тикшеренү һәм төзелеш-монтаж эшләрен гамәлгә ашыру, шулай ук индустриаль парк инфраструктурасы объектларында монтажлауга тапшырылган җиһазны сатып алу.»;

17 нче пунктта татар текстында «шул исәптән» һәм «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәү» сүзләре арасына «проектны тормышка ашыруның сигезенче елы ахырына» сүзләрен өстәргә;

19 нчы пунктның икенче абзацында татар текстында «субсидия бирү нәтиҗәләренә» сүзләре алдына «проектны тормышка ашыруның сигезенче елы ахырына» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушымтада «(Ф.Ис.Ат.ис.)» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин